1) инвестиция эшчәнлеге субъекты – инвестор, заказчы, подрядчы, инвестиция эшчәнлеге объектларыннан файдаланучы һәм инвестиция эшчәнлегендә башка катнашучылар («Россия Федерациясендә капитал салулар рәвешендә гамәлгә ашырыла торган инвестиция эшчәнлеге турында» 1999 елның 25 февралендәге 39-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясында билгеләнгән мәгънәдә);

2) инвестор – инвестиция һәм (яисә) хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Россиянең физик яисә юридик заты йә гади ширкәт шартнамәсе (уртак эшчәнлек турындагы шартнамә) буенча юридик зат төземичә эшләүче ике яисә аннан артыграк зат, дәүләт органы, җирле үзидарә органы, шулай ук «Россия Федерациясендә чит ил инвестицияләре турында» 1999 елның 9 июлендәге 160-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы икенче абзацында билгеләнгән мәгънәдә чит ил инвесторы;

3) инвестиция эшчәнлеге – табыш алу һәм (яисә) башка файдалы нәтиҗәгә ирешү максатларында инвестицияләр кертү һәм гамәли эшләр башкару;

4) капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында башкарыла торган инвестиция проектын гамәлгә ашыручы оешма – инвестиция проектын башкаручы Россия юридик заты, шул исәптән проектлау компаниясе (дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләрдән, шулай ук дәүләт унитар предприятиеләреннән һәм муниципаль унитар предприятиеләрдән тыш);

5) проектлау компаниясе – проектны башкаручы, инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен махсус булдырылган һәм түбәндәге таләпләр җыелмасына туры килә торган оешма:

а) оешманың уставында аның эшчәнлегенең предметы инвестиция проектын гамәлгә ашыру булуы турындагы нигезләмә булырга тиеш;

б) оешманың бөтен кеременнән кимендә 90 процентын оешманың инвестиция проектын гамәлгә ашырудан алган кереме тәшкил итәргә тиеш;

6) җайга салына торган оешма – табигый монополияләр субъекты һәм (яисә) үзенә карата Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт тарафыннан бәяләрне (тарифларны) җайга салу гамәлгә ашырыла торган башка оешма;

7) инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында шартнамә – инвестиция эшчәнлеге субъекты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы арасында Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектын башкару шартлары хакындагы килешү;

8) Татарстан Республикасы инвестиция меморандумы – Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеген үстерүнең өстенлекле юнәлешләрен билгеләүче, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган документ;

9) «бер тәрәзә» принцибы – инвесторга ярдәм күрсәтү максатында инвестиция эшчәнлеген тәэмин итү процедурасы, шулай ук инвестиция проектларын уңышлы

гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының үзара эшләвен оештыру.

2. Әлеге Законда кулланылучы башка төшенчәләр Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

3 статья. **Инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) инвестиция проектын гамәлгә ашыру турындагы шартнамәнең рәвешен, аны төзү һәм өзү тәртибен раслау;

2) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә бер ягы Россия Федерациясе булмаган капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешүләр төзү тәртибен, шул исәптән, «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» 2020 елның 1 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль закон) 8 статьясы таләпләрен исәпкә алып, гавами проектлау инициативасы кысаларында конкурс сайлап алуын уздыру тәртибен, мондый килешүләрне үзгәртү һәм аларның гамәлдә булуын туктату тәртибен, проектны гамәлгә ашыручы оешманың бенефициар хуҗалары хакындагы мәгълүматны ачу үзенчәлекләрен раслау;

3) үзенә карата капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешүләр төзелгән инвестиция проектын башкару этапларын мониторинглауга карата Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә аны гамәлгә ашыру тәртибен раслау;

4) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан гавами проектлау инициативасын формалаштырганда капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкару хакындагы декларация рәвешен раслау;

5) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган гомуми таләпләр нигезендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкару өчен кирәкле булган тәэмин итүче һәм (яисә) тиешле инфраструктуралар объектларын булдыру (төзү), модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү максатларында тотылган чыгымнарны, шулай ук күрсәтелгән максатларга җәлеп ителгән кредитлар һәм заемнар буенча процентлар, облигация заемнары буенча купон түләүләрен түләү чыгымнарын каплау күләмен билгеләү тәртибен раслау;

6) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең инвестиция эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы органнарын билгеләү;

7) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма

хакимияте органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә Татарстан Республикасы исеменнән капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешүләрне һәм аларга өстәмә килешүләрне имзалау, шулай ук капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру хакындагы килешүләрне өзү һәм алардан килеп чыга торган бәхәсләрне җайга салу турында карарлар кабул итү;

2) әлеге Законның 9 статьясындагы 3 өлешендә каралган бәяләүне гамәлгә ашыру;

3) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

## 2 бүлек. **Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру**

### 4 статья. **Инвестиция эшчәнлеге субъектлары хокуклары һәм бурычлары**

1. Инвесторлар Татарстан Республикасы территориясендә түбәндәге юллар белән инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бертигез хокукка ия булалар:

1) инвестиция эшчәнлеге объектларына кертелә торган акчаларны, кыйммәтле кәгазьләрне, башка мөлкәтне, шул исәптән мөлкәти хокукларны һәм акчалата бәяләнә торган башка хокукларны инвестицияләү;

2) инвестицияләр күләмнәрен һәм юнәлешләрен мөстәкыйль билгеләү, Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә башка инвестиция эшчәнлеге субъектлары белән шартнамәләр төзү;

3) инвестицияләргә җибәрелә торган акчалардан максатчан файдалануны тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

4) шартнамә шартларында һәм законнар нигезендә уртак инвестицияләүне гамәлгә ашыру максатларында үз акчаларын һәм җәлеп ителгән акчаларны башка инвесторлар акчалары белән берләштерү;

5) капитал салу объектларына һәм кертелгән капитал салулар нәтиҗәләренә хуҗа булу, алардан файдалану һәм алар белән эш итү;

6) Россия Федерациясе законнары нигезендә инвестиция проектын гамәлгә ашыру турындагы шартнамәдә һәм (яисә) дәүләт контрактында каралган башка ысуллардан файдалану.

2. Инвестиция эшчәнлеге субъектлары түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:

1) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре, федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актлар нигезендә инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашырырга;

2) дәүләт органнарының һәм вазыйфаи затларның үз компетенциясе чикләрендә куела торган таләпләрен үтәргә;

3) инвестицияләрдән максатчан билгеләнештә файдаланырга;

4) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә бүтән бурычларны башкарырга.

5 статья. **Инвестиция эшчәнлеген финанслау чыганаклары**

Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге инвесторлар тарафыннан үз акчалары һәм (яисә) җәлеп ителгән акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3 бүлек. **Инвестиция эшчәнлеген дәүләт җайга салуы һәм аны кызыксындыру чаралары**

6 статья. **Инвестиция эшчәнлеген дәүләт җайга салуы рәвешләре һәм алымнары**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция эшчәнлеге субъектлары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган инвестиция эшчәнлеген җайга салу өчен түбәндәге рәвешләрне һәм алымнарны куллана:

1) законнар нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге җирдән һәм башка табигать ресурсларыннан файдалануның ташламалы шартларын бирү;

2) финанс арендасын (лизингны) үстерү;

3) Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслана торган муниципальара инвестиция проектларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге объектларга инвестиция проектларын эшләү, раслау һәм гамәлгә ашыру;

4) законнар нигезендә инвестиция проектларына дәүләт экспертизасы үткәрү;

5) Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән инвестиция проектлары буенча дәүләт гарантияләрен конкурс нигезендә бирү;

6) законнар нигезендә региональ салымнар һәм җыемнар буенча ташламалар бирү, оешмалар табышына салым ставкаларын киметү, шулай ук салымнар һәм җыемнар буенча бирелүе законнар белән Татарстан Республикасы компетенциясенә кертелгән башка ташламалар бирү;

7) вакытлыча туктатылган һәм консервацияләнгән төзелешләрне һәм Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге объектларны инвестиция процессына җәлеп итү;

8) үз инвестиция фондларын булдыру өчен мөмкинлекләр тудыру;

9) инвестиция эшчәнлеге субъектлары рейтингын даими үткәрүне һәм аларның рейтингын бәяләүне бастырып чыгаруны гамәлгә ашыручы мәгълүмати-аналитик үзәкләр челтәрен булдыру һәм үстерү;

10) законнарда каралган очракларда электр һәм җылылык энергиясенә ташламалы тарифлар билгеләү;

11) чит илгә товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) чыгаручы инвестиция эшчәнлеге субъектларына чит ил базарларына керү өчен уңайлы шартлар тудыру;

12) технопарклар яисә индустриаль (сәнәгать) парклар инфраструктурасын булдыруга дәүләт капитал салуларын гамәлгә ашыру.

2. Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция эшчәнлеген

дәүләт җайга салуы дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык, концессия килешүләре, сәнәгать сәясәте, махсус икътисадый зоналар һәм үсеше алга киткән социаль-икътисадый территорияләр турындагы законнарда каралган башка рәвешләр һәм алымнар кулланып гамәлгә ашырылырга мөмкин.

7 статья. **Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция эшчәнлеген оештыру буенча инвесторларга дәүләт ярдәме чаралары**

1. Инвестиция проектын нәтиҗәле гамәлгә ашыру максатларында инвесторларга Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция эшчәнлеген оештыру буенча түбәндәге дәүләт ярдәме чаралары күрсәтелә:

1) республика һәм Россия базарларының структурасы һәм товар үткәрә алу мөмкинлеге турындагы, инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен кирәкле хезмәт, җитештерү һәм инфраструктура ресурслары тупланышы хакындагы мәгълүмат белән тәэмин итү;

2) инвестиция проекты гамәлгә ашырыла торган территорияләр (инвестиция мәйданчыклары) чикләрендә инфраструктура һәм кадрлар белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү;

3) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка дәүләт ярдәме чаралары.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган дәүләт ярдәме чаралары үз вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган регламент нигезендә универсаль процедура («бер тәрәзә» принцибы буенча) тәртибендә гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына инвесторның язма мөрәҗәгате буенча бирелә.

8 статья. **Чит илгә товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) чыгаручы инвестиция эшчәнлеге субъектларына дәүләт ярдәме чаралары**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз компетенциясе чикләрендә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре, Россия Федерациясе законнары нигезендә экспортны үстерүгә ярдәм чараларын (аларны кирәгенчә финанслауны да кертеп) гамәлгә ашыра, шул исәптән түбәндәгеләрне тәэмин итә:

1) сәүдә күргәзмәләре һәм ярминкәләр, махсуслаштырылган симпозиумнар, конференцияләр оештыруны һәм аларда чит илгә товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) чыгаручы инвестиция эшчәнлеге субъектларының катнашуын;

2) Россия товарларын (эшләрен, хезмәт күрсәтүләрен), интеллектуаль милек объектларын чит ил базарларына чыгару кампанияләре (шул исәптән реклама кампанияләре) үткәрүне;

3) мәгълүмати-консультация ярдәмен, шул исәптән чит ил сату базарлары, потенциаль партнерлар турында мәгълүмат алуда булышлык итүне;

4) халыкара базарларда конкурентлыкка сәләтле продукцияне (товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) җитештерүдә ярдәм итүне.

**9 статья. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектларына дәүләт ярдәме чаралары**

1. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешмага бюджет законнарында каралган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән түбәндәге чыгымнарны каплауны күздә тоткан дәүләт ярдәме чарасы бирелергә мөмкин:

1) инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган тәэмин итүче һәм (яисә) тиешле инфраструктуралар объектларын булдыру (төзү), модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге (муниципаль милектәге) инфраструктура объектларын реконструкцияләү;

2) инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган тәэмин итүче һәм (яисә) тиешле инфраструктуралар объектларын булдыру (төзү), модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге (муниципаль милектәге) инфраструктура объектларын реконструкцияләү өчен җәлеп ителгән кредитлар һәм заемнар буенча процентларны, облигация заемнары буенча купон керемен түләү.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән каплана торган чыгымнарның иң чик күләме һәм шушы чыгымнар каплануның иң чик срогы «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 15 статьясындагы 2 – 5 өлешләрендә каралган күләмнәрдән һәм сроклардан артык була алмый.

3. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчалары түбәндәге шартлар үтәлгәндә бирелә:

1) инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында барлыкка килгән һәм теркәлергә тиешле булган бөтен мөлкәти хокуклар Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлгән булса, шул исәптән кулланыла ала торган очракларда интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә һәм аларга тиңләштерелгән индивидуальләштерү чараларына хокуклар, шулай ук, инвестиция проекты күчемсез мөлкәт булдыруны күздә тотса, барлык күчемсез мөлкәт объектлары Россия Федерациясе законнары нигезендә файдалануга кертелгән булса;

2) капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешманың, инвестиция проектын гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә, капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешүнең бер ягы булган Татарстан Республикасы бюджетына түләү өчен шушы оешма исәпләп чыгарган мәҗбүри түләүләрне, атап әйткәндә, оешмалар табышына салымны, оешмалар мөлкәтенә салымны, транспорт салымын түләү буенча бурычы булмаса;

3) чыгымнарны каплау нормативлары (инфраструктура объектын булдыру (төзү), модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү максатларында тотылган чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының иң чик күләме) үтәлсә;

4) җайга салына торган оешмаларның инвестиция программаларында һәм (яисә) кулланыла ала торган очракларда икътисадның аерым тармакларын перспектив үстерү программаларында инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган тәэмин итүче һәм (яисә) тиешле инфраструктуралар объектларын булдыру (төзү), модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү проектларының булмавы тикшерелгән булса;

5) нәтиҗәләре буенча әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән дәүләт ярдәме чарасын бирү турында карар кабул ителгән инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган тәэмин итүче һәм (яисә) тиешле инфраструктуралар объектларын булдыру (төзү), модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге (муниципаль милектәге) инфраструктура объектларын реконструкцияләү, чыгымнарын финанс белән тәэмин итү вариантларына бәяләү үткәрелгән булса.

4. Әлеге статьяның 3 өлешендә каралган бәяләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан башкарыла.

5. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын бирү (тиешле инфраструктура капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешманың милкенә кергән һәм мондый оешма билгеләнгән тәртиптә инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында булдырыла торган тиешле инфраструктура объектларына хезмәт күрсәтү, аларны тоту, алардан файдалану (бетерү мөмкинлеге белән) чыгымнарын финанс белән тәэмин итү йөкләмәләрен алган очраклардан, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге (муниципаль милектәге) тиешле инфраструктура объектлары реконструкцияләнергә тиешле булган очраклардан тыш), Татарстан Республикасы тарафыннан, алга таба тиешле инфраструктураны Татарстан Республикасы дәүләт милкенә (муниципаль милеккә) яисә җайга салына торган оешма милкенә тапшырып, гамәлгә ашырыла.

6. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән чыгымнарны каплау турында карар кабул ителгәндә, инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында булдырыла һәм Татарстан Республикасы дәүләт милкенә (муниципаль милеккә) яисә җайга салына торган оешма милкенә тапшырыла торган тәэмин итүче һәм (яисә) тиешле инфраструктуралар объектларына хезмәт күрсәтүгә, аларны тотуга, алардан файдалануга (бетерү мөмкинлеге белән) Татарстан Республикасы чыгымнарын финанс белән тәэмин итү чыганаклары билгеләнергә тиеш.

7. Тиешле инфраструктура объектларын Татарстан Республикасы дәүләт милкенә (муниципаль милеккә) тапшыру яклар тарафыннан имзалана торган кабул итү-тапшыру акты нигезендә башкарыла. Кабул итү-тапшыру актын имзалау тәртибе һәм сроклары, әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, Татарстан Республикасы бюджетыннан тиешле инфраструктура объектларын булдыру (төзү), модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү максатларында тотылган чыгымнарны каплауга акчалар бирү турындагы килешү (шартнамә) белән билгеләнә.

8. Инвестиция проектын гамәлгә ашыручы, капитал салуларны яклау һәм

кызыксындыру турында килешү төзегән оешмага әлеге статьяда каралмаган ярдәм чаралары (шул исәптән дәүләт ярдәме чаралары) бирелергә мөмкин. Дәүләт ярдәме чаралары күләме, әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән дәүләт ярдәме чаралары күләменнән тыш, капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешү төзелгән яңа инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен җибәрелә торган капитал салулар күләменнән артмаска тиеш.

10 статья. **Җирле үзидарә органнары тарафыннан инвестиция эшчәнлегенә ярдәм чаралары күрсәтү**

Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвестиция эшчәнлегенә ярдәм чаралары күрсәтү рәвешләрен, тәртибен һәм шартларын мөстәкыйль билгелиләр.

11 статья. **Татарстан Республикасы Инвестиция советы**

1. Татарстан Республикасы территориясендә уңайлы инвестиция мохитен булдыру, инвестиция мохитен яхшырту, инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыруның тотрыклы шартларын тәэмин итү һәм инвестиция проектларын башкару чараларын эшләү максатларында Татарстан Республикасы Инвестиция советы төзелә.
2. Татарстан Республикасы Инвестиция советы үз составына Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, башка Татарстан Республикасы дәүләт органнары, үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы оешмалар вәкилләре керә торган, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары, эшкуарларның иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре, инвесторлар һәм экспертлар керә ала торган даими эшләүче киңәшмә органы була.
3. Татарстан Республикасы Инвестиция советы составы һәм аның эшчәнлеге тәртибе Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.

4 бүлек. **Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция эшчәнлеге субъектларына ташламалы салым салу**

12 статья. **Салым ташламалары**

1. Инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында шартнамә төзегән инвестиция эшчәнлеге субъектларына Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә салым ташламалары бирелә. Салым ташламалары бары тик инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән эшчәнлек өлешендә генә бирелә.
2. Инвестиция эшчәнлеге субъектларына Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә торган салым төрләре буенча бирелә торган салым ташламалары күләмнәре инвестиция проектын гамәлгә ашыру турындагы шартнамәдә күрсәтелә.

3. Инвестиция проектын гамәлгә ашыру турындагы шартнамә Татарстан Республикасы стратегик планлаштыру документлары һәм Татарстан Республикасы Инвестиция меморандумы белән билгеләнә торган Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре нигезендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы инвестиция эшчәнлеге субъектлары белән төзелә.

4. Инвестиция эшчәнлеге субъектлары берничә инвестиция проектын гамәлгә ашырган очракта, инвестиция проектын гамәлгә ашыру турындагы шартнамә һәр инвестиция проекты буенча аерым төзелә.

5. Инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында шартнамә төзегән инвестиция эшчәнлеге субъектлары инвестиция проектын башкаруга юнәлдерелгән хуҗалык операцияләрен күрсәтү өлешендә аерым бухгалтерлык исәбен алып баруны тәэмин итәргә тиеш.

6. Салым ташламалары инвестиция эшчәнлеге субъектларының салымнар, җыемнар буенча недоимкалары, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы (салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә кичектереп түләү, өлешләп түләү, инвестиция салым кредиты бирелгән, Россия Федерациясе законнары нигезендә реструктурлаштырылган суммалардан, затның бу суммаларны түләү бурычы үтәлгән дип тану турында үз көченә кергән суд карары булган яисә түләве салымнар һәм җыемнар хакындагы законнар нигезендә ышанычсыз дип танылган суммалардан тыш) булмаган очракта бирелә.

13 статья. **Салым ташламалары бирү сроклары**

Салым ташламалары инвестиция проектын гамәлгә ашыру турындагы шартнамә төзегән инвестиция эшчәнлеге субъектларына инвестиция проекты чыгымнарын каплау срогына, әмма инвестицияләр башлану вакытыннан алып җиде елдан да артык булмаган вакытка, бирелә. Машиналар төзү өлкәсендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы инвестиция эшчәнлеге субъектларына салым ташламалары инвестицияләр башлану вакытыннан алып 13 елга кадәр бирелергә мөмкин.

5 бүлек. **Инвестиция эшчәнлеге субъектлары хокуклары гарантияләре һәм инвестицияләрне яклау**

14 статья. **Инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру тотрыклылыгының дәүләт гарантияләре**

1. Татарстан Республикасында Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә барлык инвестиция эшчәнлеге субъектларына, милек рәвешенә карамастан, түбәндәге гарантияләр бирелә:

1) инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашырганда бертигез хокукларны тәэмин итү;

2) инвестиция проектлары турында фикер алышуда хәбәрдарлык;

3) дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм

ларның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка шикаять бирү хокукы;

4) капитал салуларны яклау.

2. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма эшчәнлеге тотрыклылыгының дәүләт гарантияләре «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 9 статьясы нигезендә бирелә.

15 статья. **Әлеге Законны куллануга бәйле рәвештә килеп чыгучы бәхәсләрне хәл итү**

Әлеге Законны куллануга бәйле рәвештә килеп чыгучы бәхәсләр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләрендә, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

16 статья. **Инвестиция эшчәнлеген туктату яисә туктатып тору**

Инвестиция эшчәнлеген туктату яисә туктатып тору Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә башкарыла.».

**2 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасында чит ил инвестицияләре турында» 1994 елның 19 июлендәге 2180-XII номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1994, № 7);

2) «Татарстан Республикасында чит ил инвестицияләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмә кертү хакында» 2001 елның 27 июнендәге 901 номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 7 – 8);

3) «Татарстан Республикасында чит ил инвестицияләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмә кертү хакында» 2003 елның 23 сентябрендәге 41-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 9 (II өлеш);

4) «Татарстан Республикасында чит ил инвестицияләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 гыйнварындагы 6-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 1);

5) «Татарстан Республикасында чит ил инвестицияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 17 маендагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 5 (I өлеш);

6) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү

турында» 2018 елның 5 мартындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 3 статьяларын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 22 (I өлеш).

**3 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) әлеге Закон үз көченә кергән көннән соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып өч ай эчендә үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә, шулай ук әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын әзерләүне һәм кабул итүне тәэмин итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 19 ноябрь
№ 72-ТРЗ